СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль, 2026 ел № 91

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында» 2023 елның 28 февралендәге 276 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2023 елның 28 февралендәге 276 номерлы карары белән (09.10.2024 № 451, 30.04.2025 № 519 карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.1 пунктчасындагы таблицаның 18 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең ярдәмчесе (мобилизация эше буенча) | 15 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http/ / vysokaya-gora. tatarstan. ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов